**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 2 сентябрь № 632

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 июль, 528 нче, 2013 ел, 5 август, 548 нче, 2014 ел, 15 март, 156 нчы, 2014 ел, 29 ноябрь, 929 нчы, 2015 ел, 30 апрель, 308 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турындагы нигезләмәдә:

3.1.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак-коммуналь хезмәтләр», «Экстремизм, дини һәм милли нигездәге каршылыклар», «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз җитештерү һәм (яки) сату (ваклап сатудан тыш)» категорияләре һәм «Коррупциягә

каршы тору» юнәлеше буенча белдерүләр бирелгән статусына карамастан, Порталда бастырылмыйлар.»;

әлеге карар белән расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы юнәлешләре, белдерүләр категорияләре һәм категорияләр модераторлары атамалары исемлегендә 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «4. | Бизнес | җәмәгать туклануы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | һәркемгә ачык челтәрдәге туклану предприятиеләре (рестораннар, барлар, кафе, кабымханәләр) хезмәтләрен оештыру |
| | | сәүдә кагыйдә-ләрен бозу | | ашамлыклар һәм ашамлык булмаган товарлар сатуны оештыру |
| | | тышкы реклама | Федераль ан-тимонополь хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) | законнарны бозып, тышкы реклама урнаштыру, рек-ламада басылган мәгълүмат белән гражданнарны һәм юридик затларны ялгыштыру |
| | | этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продук-цияне законсыз җитештерү һәм (яки) сату (ваклап сатудан тыш) | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне закон-сыз җитештерү һәм (яки) сату (ваклап сатудан тыш)». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\632.docx